**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 27 апрель № 291

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Норматив хокукый актлары бердәм банкын булдыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актларны тапшыру тәртибе турында» 2002 ел, 18 июль, 427 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Норматив хокукый актлары бердәм банкын булдыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актларны тапшыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Норматив хокукый актлары бердәм банкын булдыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актларны тапшыру тәртибе турында» 2002 ел, 18 июль, 427 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 25 гыйнвар, 34 нче, 2007 ел, 17 гыйнвар, 8 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Норматив хокукый актлары бердәм банкын булдыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актларны тапшыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарын» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «шулай ук норматив характерда булган Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарын хокукый актлары һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «һәм кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бердәм банкка шулай ук Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән прокуратура органнары

протестлары һәм гаризалары, Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары һәм билгеләмәләре, бүтән судлар һәм башка дәүләт органнары карарлары кертелә.»;

9 пунктны көчен югалткан дип танырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы норматив хокукый актлар (республика башкарма хакимияте органнары актларыннан гайре) кергән көннән соң дүрт көн эчендә актларның күчермәләрен билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары федераль регистрына кертү өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юллый.

Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары күчермәләре Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң дүрт көн эчендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юллана.»;

11 пунктны көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\291.doc